| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**25.03.2022** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 668** |
|---|---|---|

Зеленодольск шәһәре Башкарма комитетының, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең, аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Норматив хокукый актларны актуальләштерү максатыннан, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск шәһәре Башкарма комитетының түбәндәге карарларының үз көчләрен югалткан дип таныргa:

- «Чираттагы елга һәм план чорына «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты проектын төзегәндә кирәкле тәртипләрне раслау турында» 2008 елның 26 июнендәге 01-08-7 нчы номерлы карары;
- «Зеленодольск шәһәре Башкарма комитетының муниципаль ихтыяҗлары өчен заказлар урнаштыру буенча Бердәм конкурс, аукцион һәм котировка комиссиясе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2009 елның 16 гыйнварындагы 01-08-1 нчы номерлы карары;
- «Зеленодольск шәһәрендә «Автономияле учреждениеләр турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2009 елның 17 апрелендәге 01-08-99 нчы номерлы карары;
- «Янгыннан зыян күргән Зеленодольск шәһәре гражданнарына бер тапкыр матди ярдәм күрсәтү турында нигезләмәне раслау хакында» 2009 елның 8 июлендәге 01-08-204 нче номерлы карары;
- «Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә янгын куркынычсызлыгы чараларын әзерләүне һәм укытуны оештыру турында» 2009 елның 29 июлендәге 01-08-224 нче номерлы;
- «Янгыннан ирекле саклау эшчәнлеген булдыру һәм оештыру турында, аның янгыннан саклануның башка төрләре белән хезмәттәшлеге тәртибе турында». 2009 елның 29 июлендәге 01-08-225 нче номерлы карары.

2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең түбәндәге карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында:

- «Наркотик чараларны һәм аларның законсыз әйләнешен яман ният белән куллануга каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия төзү турында» 2006 елның 15 декабрендәге 1209 нчы номерлы карары;

- «Наркотик чараларны һәм аларның законсыз әйләнешен яман ният белән куллануга каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия төзү турында» Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2009 елның 15 декабрендәге 1209 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 08 октябрендәге 1380 нче номерлы карары;
- «Зеленодольск муниципаль районы территориясендә янгынга каршы махсус режим кертү турында» 2008 елның 23 апрелендәге 780 нче номерлы карары;
- «Зеленодольск муниципаль районы Дәүләт урман фондында урман янгыннарын сүндерүне оештыру чаралары турында» 2008 елның 24 апрелендәге 783 нче номерлы карары;
- «Зеленодольск муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән төзелешне, капиталь ремонтлауны, проект-тикшеренү, геологик-разведка һәм технологик эшләрне финанслау регламентын раслау турында» 2008 елның 08 маендагы 914нче номерлы карары.

3. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http:zelenodolsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Җитәкче И.Р. Ганиев